| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2026 Балык Бистәсе штп. №88пи

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү турында

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар исәбеннән махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә башкаручы гражданнар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) каты ягулык (утын), ашлык һәм печән белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтүне дә кертеп, өстәмә ярдәм чарасы билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү Тәртибен расларга.

3. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм чаралары күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанслау өстәмә бүлеп бирелгән акчалар һәм хәйриячеләр акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
13.04.2026 №88пи карары белән
расланган

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм чарасы күрсәтү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарның (вафат булганнарның) гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) каты ягулык (утын), ашлык һәм печән белән тәэмин итү рәвешендә, аларны илтүне дә кертеп, өстәмә ярдәм чарасы бирү шартларын һәм күләмнәрен билгели.

2. Өстәмә ярдәм чарасы түбәндәге күләмнәрдә мохтаҗлык булганда календарь елга бер мәртәбә күрсәтелә:

- бары тик мич белән җылытыла, шул исәптән утын белән эшли торган автоном җылыту системасы белән җылытыла (алга таба-мич белән җылытыла) торган бер бүлмәгә яисә мунчага 5 (биш)куб. метр күләмендә каты ягулык (утын);
- ашлык - бер гаиләгә 1 центнер күләмендә;
- печән - бер гаиләгә 500 кг.күләмендә.

3. Әлеге Тәртиптә мохтаҗлык дигәндә аңлашыла:

- каты ягулык өчен-махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзасы теркәлгән мунча яисә мич белән җылытыла торган торак урын булу;
- ашлык өчен-хуҗалыкта авыл хуҗалыгы кошларының һәм/яисә ашлык белән тукландыруны таләп итүче терлекләрнең булуы;
- печән өчен – шәхси ярдәмче хуҗалыкта печән ашатуны таләп итүче терлекләр булу.

## II. Ярдәм алучылар категорияләре

4. Өстәмә ярдәм чарасы күрсәтелә торган махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәге затлар аңлашыла (алга таба – гаилә әгъзасы):

- махсус хәрби операциядә катнашучының яшәү яисә булу урыны буенча теркәлгән хатыны (ире) һәм (яисә) аның балигъ булмаган балалары;
- махсус хәрби операциядә катнашучының ата-анасы (ата-аналары).

5. Өстәмә ярдәм календарь елда махсус хәрби операциядә катнашучының гаиләсенең бер әгъзасына гына күрсәтелергә мөмкин. Махсус хәрби операциядә катнашучы бер кешенең берничә гаилә әгъзасыннан гаризалар кергән очракта, беренче чиратта карау хокукы балигъ булмаган баласы булган ир яисә хатынга бирелә.

## III. Ярдәм күрсәтү тәртибе

6. Гаилә әгъзаларына өстәмә ярдәм күрсәтү мөрәҗәгать итү характерында була һәм календарь елга бер тапкырдан да ешрак күрсәтелми.

7. Өстәмә ярдәм чарасын алу максатында гаилә әгъзасы авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетына (алга таба – җирлек башкарма комитетына) түбәндәге документларны кушып гариза бирә:

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;
- махсус хәрби операциядә катнашучы статусын раслый торган документ;
- гаилә әгъзасының һәм махсус хәрби операциядә катнашучының туганлыгын (үзлеген) раслый торган документ (туу (уллыкка алу) турында таныклык, никах турында таныклык, туганлыкны (үзлеген) раслый торган башка документ);
- мич белән җылытыла торган бина булу турында (каты ягулык алу өчен)мәгълүмат булган документ;
-авыл хуҗалыгы кошларының һәм/яисә терлекләрнең булуын раслый торган документ ( ашлык алу өчен);
- авыл хуҗалыгы терлекләре белән шәхси ярдәмче хуҗалык булуын раслый торган документ (печән алу өчен);
- махсус хәрби операциядә катнашучының вафат булуы турында таныклык-махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучының гаилә әгъзалары булган затлар өчен;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

8. Гаризада күрсәтелә:

- сорала торган ярдәм төре (каты ягулык, ашлык, печән яисә аларның комбинациясе);
- сорала торган ярдәмгә мохтаҗлыкны нигезләү;
- махсус хәрби операциядә катнашучының гаиләсенең башка әгъзалары турында белешмәләр;
- кабул ителгән карар турында хәбәр итү ысулы (шул исәптән почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы).

9. Килгән документлар җирлек Башкарма комитеты белгече тарафыннан аларны тапшырган көнне үк теркәлә.

Документларны караганнан һәм тикшергәннән соң, җирлек башкарма комитеты документларның тулы пакетын Балык Бистәсе муниципаль районындагы МТЗ һәм ТР СЗ халыкны социаль яклау бүлегенә (алга таба-халыкны социаль яклау бүлеге) алга таба ярдәм итү чараларын рәсмиләштерү һәм күрсәтү өчен җибәрә.

10. Гаилә әгъзасы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

11. Гариза Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләре белән хезмәттәшлек итү штабында (алга таба-Штаб) ул теркәлгән көннән алып 30 (утыз) календарь көннән артмаган вакытта карала.

## IV. Карар кабул итү

12. Гаризаны карау йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

- сорала торган ярдәм төрләрен (каты ягулык, ашлык, печән)тәэмин итү һәм илтеп бирү турында;

-сорала торган ярдәм төрләрен тәэмин итүдән һәм китерүдән баш тарту, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп.

13. Күрсәтелгән карар язма хәбәрнамә рәвешендә гаризаны карау срогыннан да соңга калмыйча җирлек башкарма комитетына җибәрелә.

14. Баш тарту өчен нигезләр булып тора:

- әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән затлар категориясенә туры килмәве;

- тапшырылган документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүматны ачыклау;

- сорала торган ярдәмгә мохтаҗлык булмау;

- агымдагы календарь елда сорала торган ярдәм төрен күрсәтү;

- агымдагы календарь елда махсус хәрби операциядә катнашучының гаиләсенең башка әгъзасына өстәмә ярдәм күрсәтү;

- гаилә әгъзасы тарафыннан гаризаны кире алу;

- әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын тапшыру.

15. Баш тартуга нигез булган сәбәпләрне бетергәндә, өстәмә ярдәм күрсәтү өчен документлар җирлек башкарма комитетына әлеге Тәртип нигезендә яңадан тапшырылырга мөмкин.

## V. Китереп бирү сроклары һәм тәртибе

16. Гаилә әгъзасы күрсәткән адрес буенча илтеп бирү түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

каты ягулык – май-октябрь;

- ашлык-сентябрь-ноябрь;

- печән-июнь-август.

17. Каты ягулык, ашлык һәм/яисә печән алу факты фотофиксация һәм гаилә әгъзасы һәм җирлек башкарма комитеты вәкиле кул куйган кабул итү-тапшыру акты белән раслана.

18. Штаб, ярдәм төре, күләме, бирү датасы һәм алучы турында мәгълүматлар күрсәтеп, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүнең өстәмә чараларының исәбен алып бара.